**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР  ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ ПР-287

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының район звеносы турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 октябрендәге ПР-270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 18 июлендәге «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 840 номерлы карары нигезендә һәм районда гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының район звеносы эшчәнлеген алга таба камилләштерү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 октябрендәге ПР-270 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының район звеносы турындагы нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 24 пункттагы «гадәттән тыш хәл режимында» пунктчасын өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«Халыкның һәм территорияләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары, кабул ителә торган алымнар һәм яклау ысуллары, гамәлләр тәртибе, гадәттән тыш хәл зонасында үз-үзләрен тоту кагыйдәләре, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм зыян күрүчеләрне социаль яклау өлкәсендә гражданнарның хокуклары турында, шул исәптән Россия Федерациясе законнарында каралган түләүләрне алу хокукы, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә югалган документларны торгызу тәртибе турында мәгълүмат бирү.».

2. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 июлендәге ПР-183 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 05 сентябрендәге ПР-216 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми мәгълүматында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен  контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе  И.Ш. Бариев